| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| С О В Е Т<br>Нижнекамского муниципального района | Түбән Кама муниципаль районы<br>С О В Е Т Ы |
| 423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12<br>тел./факс (8555) 41-70-00 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12<br>тел./факс (8555) 41-70-00 |


**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 24** **11 апреля 2019 года**

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә куллануга тапшыру өчен һәм (яки)куллану өчен билгеләнгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, бастырып чыгару тәртибе хакында Нигезләмәне раслау турында» 53 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасының «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә куллануга тапшыру өчен һәм (яки)куллану өчен билгеләнгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, бастырып чыгару тәртибе хакында Нигезләмәне раслау турында» 53 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга.

карарның 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3 «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ

номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда, мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүле читләштерүдән тыш, исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәт шәхси милеккә читләштерелергә тиеш түгел.»

2. Әлеге карарны гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы А.Р.Метшин